ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07 05 2020 г. № 280

Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә эш көннәре булмаган чорга балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвеннән азат итү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә эшләми торган көннәрне игълан итү турында» 2020 елның 25 мартындагы 206 номерлы, «Яңа короновирус инфекциясе (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2020 елның 2 апрелендәге 239 номерлы указларын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Эшләми торган көннәрдә дежур төркемнәр турында» 2020 елның 27 мартындагы 3845/20 номерлы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү максатларында, эшләми торган көннәрдә дежур төркемнәр турында» 2020 елның 4 апрелендәге 38454136/20 номерлы, «Эш көне булмаган көннәрдә балалар бакчаларында абонент түләве турында» 2020 елның 29 апрелендәге 4921/20 номерлы хатларын исәпкә алып, карар бирәм:

1. Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Президенты Указлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән эш көннәре булмаган чорда балалары килмәгән көннәргә ата-аналарны (законлы вәкилләрне) Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвеннән азат итәргә.

2. Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Бюджет һәм финанслар департаменты» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарның 1 пункты нигезендә мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен финанслауны тәэмин итәргә.

3. Түбән Кама муниципаль районының «Мәктәпкәчә белем бирү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чорда ата-ана (законлы вәкилләр) керткән абонент түләвен мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре тарафыннан яңадан исәпләүне гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2020 елның 30 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе башлыгы А.Р. Фәретдиновка йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов